**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 18 сентябрь № 690

г. Казань

«Алкоголь инспекциясе» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасы турында

Татарстан Республикасының Этил спиртын, алкогольле продукцияне җитештерүне, сатуны һәм аның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенең дәүләт вазыйфаларын һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүне мәгълүмати тәэмин итүне гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеген автоматлаштыру максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Алкоголь инспекциясе» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасын төзү.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

«Алкоголь инспекциясе» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасының дәүләт заказчысы итеп – Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын;

«Алкоголь инспекциясе» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасының вазыйфаи операторы һәм мәгълүматлар базасы операторы итеп – Татарстан Республикасының Этил спиртын, алкогольле продукцияне җитештерүне, сатуны һәм аның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясен;

«Алкоголь инспекциясе» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасының техник операторы итеп – «Татарстан Республикасының мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесен, аңарга «Алкоголь инспекциясе» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасын үстерү һәм техник ярдәм күрсәтү чараларын үткәрүне тәэмин итү өлешендә тиешле вәкаләтләр биреп.

3. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына, Татарстан Республикасының Этил спиртын, алкогольле продукцияне җитештерүне, сатуны һәм аның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе белән берлектә, әлеге

карар үз көченә кергән көннән соң 60 көн эчендә, «Алкоголь инспекциясе» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасын кулланучыларның эш регламентын исәпкә алып, «Алкоголь инспекциясе» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасы турында нигезләмәне эшләргә һәм расларга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\690.docx